**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

от 06 декабря 2013 года г. Казань № 10-55/кс

***Чиста су һәм су бүлү тарифларын билгеләү хакында***

07.12.2011 №416-ФЗ “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында” Федераль законы нигезендә, 13.05.2013 №406 “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу” Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 21.10.2013 №192-э/3 «Уртача 2014 елга Россия Федерациясе субъектларында, су белән тәэмин итү һәм су бүлү тарифларын максималь үзгәртү чик индексын билгеләү” Тарифлар буенча Федераль хезмәт боерыгы, 15.06.2010 №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты кагыйдәнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. Салкын су һәм су бүлү белән тәэмин итүче оешмалар өчен чиста су һәм су бүлү тарифларын, әлеге карарның кушымтасына таянып календарь бүленеш нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 01 гыйнварыннан алып 2014 елның 31 декаберенә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның кушымтасында билгеләнгән салкын су һәм су бүлүне тәэмин итүче оешмалар, 17 гыйнвар 2013 елгы №6 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән гамәлгә кертелгән, су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә информацияне ачу стандартлары нигезендә, алдагы җайга салу дәверенә тарифларны билгеләү хакында карар кабул ителгәч 30 көннән дә соң түгел, ирекле кулланышта булган мәгълүматны ачып бирергә.

4. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты карарына Кушымта
06 декабрь 2013 ел № 10-55/кс

## Календарь бүленешкә нигезләнгән, салкын су һәм су бүлүне тәэмин итүче оешмаларның чиста су һәм су бүлүгә караган тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су бүлүче оешманың, муниципаль үзидарәнең исеме | Чиста су тарифлары (берставкалы), сум./куб.м | | Салкын суны транспортлау тарифлары (берставкалы), сум./куб.м | | Су бүлү тарифлары (берставкалы), сум./куб.м | | Агып төшә торган суны транспортлау тарифлары (берставкалы), сум./куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01. 2014 – 30.06. 2014 | 01.07. 2014 -31.12. 2014. | 01.01. 2014 - 30.06. 2014 | 01.07. 2014-31.12. 2014 | 01.01. 2014 - 30.06. 2014 | 01.07. 2014-31.12. 2014 | 01.01. 2014 -30.06. 2014 | 01.07. 2014-31.12. 2014 |
| | Әлмәт муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | ҖЧҖ «Торак коммуналь җитештерү – хезмәт күрсәтү предприятиясе «ИНФОСЕРВИС»*: | | | | | | | | |
| 1.1 | Ерсубай авыл җирлеге кулланучылары | 10,00 | 10,64 | | | | | | |
| 1.2 | Кузайкино авыл җирлеге кулланучылары | 18,44 | 19,44 | | | 11,32 | 11,87 | | |
| 2 | ҖЧҖ «ШАНС»* | 21,01 | 21,66 | | | | | | |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | | | | | | | |
| 3 | ААҖ «Югары Ослан районы коммуналь челтәре»: | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Торак секторы кулланучылары (тарифларда ӨБС исәпкә алынган)** | 38,30 | 38,30 | | | 42,69 | 42,69 | | |
| | Башка кулланучылар (тарифларда ӨБС исәпкә алынмаган) | 32,46 | 32,46 | | | 36,18 | 36,18 | | |
| | Алабуга муниципаль районы | | | | | | | | |
| 4 | ААҖ “Алабуга” җитештерү тибындагы махсус икътисади зона (тарифларда ӨБС исәпкә алынмаган) | 35,06 | 35,06 | | | 50,06 | 50,06 | | |
| | Саба муниципаль районы | | | | | | | | |
| 5 | ААҖ “Саба районы Шәмәрдән МПП ЖКХ”* | 22,92 | 23,86 | | | 34,96 | 35,64 | | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | | |
| 6 | ААҖ “Суднолар йөрү компаниясе “Татфлот” (тарифы указаны без учета НДС) | | | 3,03 | 3,03 | | | 4,84 | 4,84 |

<*> Россия Федерациясе Салымнар кодексының 168 статьяның 6 пунктын тормышка ашыру максатын күздә тотып аерылып бирелгән
<**> гадиләштерелгән салым алу системасы кулланыла

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты,
Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештуры һәм җайга салу бүлеге